ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ТАТАРСКО-ТОЛКИШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЧИСТОПОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

422961, Республика Татарстан,
Чистопольский район,
село.Татарский Толкиш, ул.Советская, дом 2

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ТАТАР ТАЛКЫШЫ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

422961, Татарстан Республикасы,
Чистай районы, Татар Талкышы авылы,
Совет урамы, 2 нче йорт.

тел. 884342 3-32-23, e-mail: Ctp.Ttolk@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**№ 4** **«27» февраль 2019 ел**

Муниципаль хезмәтләр
күрсәтүнең административ
регламентына үзгәрешләр
кертү турында

Чистай шәһәр прокурорының “Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүне оештыру турындагы законны бозуларны бетерү турында”гы 31.01. 2019 елгы 02-08-02-2018 нче номерлы күрсәтмәсен карап, 2010 елның 27 июлендә кабул ителгән “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында”гы 210 нчы номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 18 июнендә кабул ителгән “Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 8 нче карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 18 июнендә кабул ителгән “Нотариаль гамәлләр башкару : васыятьнамәне раслау һәм ышаныч кәгазен раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы 7нче карары белән расланган нотариаль гамәлләр башкару: васыятьнамәне раслау һәм ышаныч кәгазен раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлеге башкарма комитетының 2018 елның 18 июнендә кабул ителгән “Документлар күчермәләренең һәм алардан алынган өземтәләрнең дөреслеген раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында”гы

6нчы карары белән расланган документлар күчермәләренең һәм алардан алынган өземтәләрнең дөреслеген раслау буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1.3.3нче пунктта:

беренче абзацта “ муниципаль хезмәт турындагы” дигән сүзләрдән соң “, шулай ук башкарма комитетның урнашу урыны һәм эш графигы турында ” дигән сүзләрне өстәргә;

1нче пунктчаны “Мәгълүмат” дигән сүздән соң “Татарстан Республикасының дәүләт телләрендә” дигән сүзләр белән тулыландырырга;

1.2. 1.5.нче пунктта “дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күп функцияле үзәкнең читтәге эш урыны” дигән билгеләмә төшенчәсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күп функцияле үзәкнең читтәге эш урыны – дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күп функцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур подразделениесе (офис), ул Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 22.12.2012 елгы “Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күп функцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру Кагыйдәләрен раслау турында”гы 1376 нчы карары белән расланган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күп функцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру Кагыйдәсенең 34нче пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районының шәһәр яки авыл җирлегендә оештырылган.

1.3. 5.1нче пунктта:

3нче пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“3) гариза бирүчедән Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районының норматив хокукый актлары белән каралмаган документларны яки мәгълүматны таләп итү яисә гамәлләр кылу;”;

түбәндәге эчтәлектәге 10нчы пунктча белән тулыландырырга:

“10) гариза бирүчедән муниципаль хезмәт күрсәткәндә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәк булган документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны (аларның булмаулары һәм (яки) дөрес булмаулары) таләп итү яисә 210 нчы Федераль законның 7нче маддәсенең 1 өлешенең 4 нче пунктында каралган очраклардан кала.”;

1.4. түбәндәге эчтәлектәге 5.9. һәм 5.10нчы пунктлар белән тулыландырырга:

“5.9. Шикаять канәгатьләндерерлек дип табылган очракта гариза бирүчегә җавапта муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган бозуларны тиз арада бетерү максатында башкарма комитет тарафыннан тормышка ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китергән уңайсызлыклар өчен гафу үтенәләр һәм муниципаль хезмәт алу максатында гариза бирүчегә алга таба нәрсә эшләргә кирәклеге турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.10. Шикаять канәгатьләндерерлек дип табылмаган очракта гариза бирүчегә җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында аргументлаштырылган аңлатма, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять белдерү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.” .

2. Әлеге карарны Татар Талкышы авыл җирлеге Советының мәгълүмат стендлары аша халыкка белдерергә һәм  шулай ук Чистай муниципаль районының http:/chistopol.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштырырга.

Татар Талкышы авыл җирлеге
башлыгы М.М. Вәлиев